**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясепоселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**21.12.2023** **№ 1938**

Җир кишәрлегеннән файдаланунның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында

М.В. Львованың 2070 кв.м. мәйданлы 16:16:190301:528 кадастр номерлы җир кишәрлегенә карата файдаланунның «Кибетләр» шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы гаризасын карап, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 37 ст., 39 ст., «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 ст., «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2020 елның 10 ноябрендәге П/0412 номерлы Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәте боерыгына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2023 елның 29 сентябрендәге 324 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә, 2023 елның 10 ноябрендәге гавами тыңлаулар беркетмәсен исәпкә алып, Башкарма комитет КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау авыл җирлеге, Эстачи ав., адресы буенча урнашкан, «Торак пунктлар җирләре» рөхсәт ителгән файдалану төре булган 2070 кв.м. мәйданлы 16:16:190301:528 кадастр номерлы җир кишәрлегенә файдаланунның шартлы рөхсәт ителгән төренә - «Кибетләр» төренә рөхсәт бирергә.
2. «Татарстан Республикасы Биектау районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль казна учреждениесенә әлеге карарны теркәгән көннән алып ун эш көне эчендә Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрына тиешле белешмәләр кертү өчен әлеге карарның күчермәсен җибәрергә.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Ф. Хәкимуллинга йөкләргә.

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин